**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 августындагы 3500 номерлы карары**

**Казан шәһәре Совет районының Шуртыгин урамында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 85 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:060616:37;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы;
- билгеләү максаты: җирле әһәмияттәге ТП-986 трансформатор подстанциясе электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-986 трансформатор подстанциясенә милек хокукы (2001 елның 26 декабрендәге №16-50.3-23.2001-1364.3) теркәлгән.

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 22 августындагы
3500 номерлы карары белән
расланды

**Җир кишәрлегенең бер өлешенә**
**ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**



Масштаб 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | булган җир кишәрлекләренең чиге |
| | кызыл линияләр |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:060616 | кадастр кварталы |
| 16:50:060616:37 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир |